| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>2017 ел 28 февраль | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>№ 381 |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү » 2013 елның 01 октябрендәге 2220 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручыбелем бирү оешмаларына йөрүче балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 08 февралендәге 20-13/1392 номерлы хаты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү » 2013 елның 01 октябрендәге 2220 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең текстына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 нче бүлегендәге 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Компенсация алуга хокукны билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган кереме «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр

бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

1.2. «Гомуми нигезләмәләр» 1нче бүлегенә түбәндәге 1.5 пунктны өстәргә:

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба исәп - хисап чоры).

1.3. «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» 2 нче бүлегенең 2.1 пунктындагы b пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

өстәмә компенсация бирү турында гариза бирелгән айга кадәрге алты айда гаиләнең һәр әгъзасы керемнәре турында документлар.

2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 01 октябрендәге 2220 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә өстәмәләр кертү хакында»2016 елның 12 маендагы 1250 номерлы карары белән расланган «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» 2 нче бүлегенең 2.7 пунктына үзгәрешләр кертергә:

Махсуслаштырылган оешмага Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекнең төбәк системаларын кулланып, түләүләр суммасы һәм физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан исәпләнгән башка бүләкләүләр турында мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә торган мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң, компенсация билгеләү гаризада күрсәтелгән аның ризалыгы белән, гариза бирүченең компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать итү аена кадәрге 12 айның соңгы 6 аенда, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интренет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин